**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.12.2019 № 1098

2020 елда Нурлат муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре тарафыннан җәмәгать эшләрен оештыру турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 19.04.1991 ел, № 1032-1 Россия Федерациясе Законын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җәмәгать эшләрен оештыру турында нигезләмәне раслау турында» 1997 ел, 14 июль, 875 нче карарын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 99 нчы карарын үтәү, эшсезлекнең икътисади нәтиҗәләрен йомшарту һәм вакытлыча эш белән тәэмин ителмәгән халыкка матди ярдәм күрсәтү, шул ук вакытта хезмәткә мотивацияне саклау йөзеннән, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елда җәмәгать эшләре статусы бирелүче Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырылучы эшчәнлек төрләре исемлеген расларга (1 нче кушымта).

2. Нурлат муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- һәр айның 1 числосына кадәр җәмәгать эшләре буенча тәкъдимнәрне «Нурлат шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә җибәрергә;
- «Нурлат шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ белән килешүләр буенча җәмәгать эшләрен оештыру һәм үткәрүне тәэмин итәргә;
- җәмәгать эшләрен башкару өчен халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте тарафыннан җибәрелгән гражданнарны эшкә урнаштырырга һәм үз вакытында хезмәт хакы түләргә.

3. «Нурлат шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУнә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- Нурлат муниципаль районы эш бирүчеләре тарафыннан игълан ителгән җәмәгать эшләренә эшсез гражданнарның оператив рәвештә җибәрелүләрен тәэмин итәргә;
- җәмәгать эшләрендә мәшгуль булган эшсез гражданнарга матди ярдәм күрсәтүне вакытында башкарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л. Н. Маняпов

ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының .2019 елның 1098 карарына 1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы территориясендә башкарыла торган төп иҗтимагый эш төрләре исемлеге

**Авыл хуҗалыгы**

Авыл хуҗалыгында корткычларга каршы көрәш;
территорияне төзекләндерү;
яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерү һәм җыеп алу;
техник культуралар игү һәм урып-җыю;
үсентеләр сайлау;
органик чимал чыгару;
терлек сую;
печән, азык әзерләү;
авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, саклау һәм эшкәртү;
торф чүлмәкләре ясау;
терлекчелек биналарын механикалаштыру;
архив документларын эшкәртү;
азык культураларын эшкәртү һәм җыеп алу;
агач кисү;
авыл хуҗалыгы техникасына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау;
авыл хуҗалыгы объектлары түбәләрен кардан чистарту;
бәрәңге аралау;
чәчүгә әзерлек һәм чәчү эшләре;
туфрак әзерләү;
элеваторларны эшкә әзерләү;
агач үсентеләре утырту;
утыртылган үсенте араларын эшкәртү;
вахтер, сакчы булып эшләү;
җәнлек үрчетү фермасында эшләү;
агач ярдыручы булып эшләү;
ындырда, ашлык кабул итү пунктында эшләү;
сыер саву операторы булып эшләү;
теплица-бакча хуҗалыкларында эшләү;
терлекләрне үрчетү һәм көтү белән бәйле вакытлыча характердагы эшләр;
азык-төлек һәм эшкәртү предприятиеләрен реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан җиһазландыру эшләре;
иске ферма биналарын сүтү;
кычыткан чабу;
терлекчелек һәм склад биналарын ремонтлау;
буш савытлар әзерләү һәм ремонтлау;
хайваннарга ашату өчен дару үләннәре җыю;
җиләк җыю;
авыл хуҗалыгы язгы кыр эшләрен башкарганда сезонлы эшләр;

салам эскертләү;
балта эшләре;
яшелчә һәм җиләк-җимеш аралау;
хайваннарның йоннарын кырку;
төзелеш-ремонт эшләре;
кырдан ташлар җыю;
икмәк кабул итү пункты территориясен җыештыру;
урып-җыю эшләре;
яшелчә һәм җиләк-җимешне саклауга кую;
чүп утау;
хайваннар карау;
мамык йон тарау;
торак-коммуналь хуҗалыкны эксплуатацияләү;
башка эшләр.

**Төзелеш**
Тапшырыла торган объектларны төзекләндерү;
Җир эшләре;
буяу һәм штукатурлау эшләре;
бүрәнә каезлау;
төзелеш материалларын ташу;
су, газ, канализация һәм башка коммуникацияләр салганда ярдәмче, өстәмә һәм башка эшләр, авыл хуҗалыгында сугару (ирригация) эшләрен үткәрү һ.б.;
кирпеч ясау;
төзелеш материаллары җитештерү;
иске кирпеч өемнәрен сүтү;
терлекчелек биналарын ремонтлау;
социаль-мәдәни-көнкүреш объектларын ремонтлау;
башка төрле эшләр.

**Сәнәгать**
предприятиеләрдә үзгәртеп төзү һәм үзгәртеп  кору чорында квалификацияле булмаган эшләр башкару;
агач эшкәртү;
бина һәм цехларда косметик ремонт ясау;
җитештерү һәм җитештерүле булмаган биналарның тәрәзәләрен юу;
предприятиеләр территорияләрен кардан чистарту;
кыргый җиләк-җимешне эшкәртү;
урман эшкәртү;
авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү;
теплица хуҗалыкларында, ит комбинатларында, җитен заводларында, кирпеч заводларында һәм башка предприятиеләрдә ярдәмче эшләр;
махсус кием тегү;
заводта сөт кабул итү;
агач материаллары җитештерү, буралар ясау һәм башкалар;
тегү цехларында эшләү;
Биналарга, корылмаларга хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау эшләре;

күмерне аеру һәм юдыру эшләре;
электр тапшыру линияләре трассаларын чистарту һәм башкалар;
буш саытлар әзерләү һәм ремонтлау;
җиһаз ремонтлау;
икенчел чимал һәм калдыкларны җыю һәм эшкәртү;
папкалар ябыштыру;
балта эшләре;
пыяла савытлар аралау;
җыештыру, төзекләндерү һәм территорияне яшелләндерү;
көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртү;
сызым эшләре;
башка төрле эшләр.

**Урман хуҗалыгы**
Урман корткычларына каршы көрәш;
янгыннардан соң урманнарны торгызу (кисү, сирәкләү);
куаклар, агачлар кисү, үлән чабу, территорияне чүп-чардан чистарту, чүп-чар чыгару эшләре;
чыршы һәм чыршы букетлары әзерләү;
урман, үрү өчен чыбык, салам хәзерләү;
урман орлыгы әзерләү;
яшелләндерү;
урман делянкаларын киселгән калдыклардан чистарту;
питомниклар һәм урман посадкалары утырту өчен туфрак әзерләү, үсентеләрне карау;
үсентеләрне утырту, алар артыннан агротехник карау;
агач ярдыруда эшләү;
урманнарны чүп-чардан һәм пычрактан чистарту;
дару үләннәре, кыргый үсүче җиләк-җимеш, чикләвек, ылыслы агач күркәләре җыю һәм әзерләү;
урман-парк хуҗалыгын саклау һәм үстерү;
урман хуҗалыкларында исәп эшләре;
урманда киселгән агачларны аралап төзү;
башка төрле эшләр.

**Юл төзелеше**
тротуарларны һәм килү юлларын төзекләндерү һәм урнаштыру;
посадкалар утырту һәм үстерү, күз күременә комачаулаган куакларны кисү;
койма кую өчен җир эшләре;
кар тоту җайланмалары әзерләү, кую һәм ремонтлау;
юлларны төзекләндерү элементларын буяу, аларны чисталыкта һәм тәртиптә тоту;
юл кырыйларында су агызу өчен җайланмалар урнаштыру;
юл өслекләрен пычрактан һәм кардан чистарту;
торбаларның тишекләрен ачу һәм ябу, күперләр һәм юлүткәргечләр элементларын пычрактан, кардан һәм боздан чистарту;
юл читен планлаштыру;
суүткәргеч системасын эшкә яраклы хәлдә тоту;

җир өслегендә тотрыклы катлам булдыру буенча кирәкле агротехник чаралар үткәрү;
юллар төзегәндә һәм ремонтлаганда эшләр;
асфальт җәю;
юл конструкцияләрен ремонтлау;
юл өслеген төзү һәм ремонтлау;
күперләр төзекләндерү;
үләннәрне чабу һәм юл кырыйларында куакларны кисү, чыбык-куакларны җыештыру;
автобус тукталышларын, мәйданчыкларны һәм аларны төзекләндерү элементларын чиста һәм тәртиптә тоту;
җәяүлеләр өчен тротуарлар төзү;
кар тота торган урман полосаларын карау;
башка төрле эшләр.

**Сәүдә һәм җәмәгать туклануы**
Базар территориясен төзекләндерү;
Вак кибетләрдә сату;
савыт-саба юу;
халыкны сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү;
яшелчәсаклагычларны чистарту һәм әзерләү;
Йөк ташу;
Буш савытлар әзерләү һәм ремонтлау;
ремонт-торгызу һәм кар чистарту эшләре;
кафе, ашханә бүлмәләрен җыештыру һәм башкалар;
Әзер продукцияне төргәкләү;
башка төрле эшләр.

**Торак-коммуналь хуҗалыгы**
бордюрларны бетонлаштыру һәм буяу;
территорияләрне төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту;
истәлек билгеләрен торгызу һәм алмаштыру;
храмнарны, мәчетләрне торгызу һәм реставрацияләү ;
тарихи-архитектура һәйкәлләрен, ял итү зоналарын, мәдәният паркларын, скверларны торгызу һәм саклау: яшелләндерү, утырту, утау, клумбаларга су сибү, агарту, агачлар утырту, чүп үләннәрен утау һәм җыю һ.б..;
территорияләрне, сулыкларны экологик савыктыру чаралары;
пляжларны чистарту;
Гравий һәм ком сибү;
хәрби каберлекләрне, мемориалларны, туганнар каберлекләрен, зиратларны тәртипкә китерү, күмү урыннарын карап тоту һәм башкалар.;
Ягулык сезонына әзерлек эше;
энергия, газ, җылылык һәм су белән тәэмин итү һәм канализацияне карап тоту һәм үстерү буенча эшләр һәм башкалар;
торак пунктлар территорияләрен экологик иминләштерү эше;
торакны газлаштырганда эшләр;

иске йортларны сүтү;
карны чистарту һәм шугалаклар ясау;
күперләр төзекләндерү;
мичләр ремонтлау;
квартал эчендәге территорияләрне һәм чүп-чардан һәм көнкүреш калдыкларыннан контейнер мәйданчыкларын санитар чистарту;
үз белдеге белән төзелгән корылмаларны җимерү;
торак фондын һәм социаль-мәдәни көнкүреш объектларын (балалар мәктәпкәчә учреждениеләре, спорт мәйданчыкларын, мәдәният учреждениеләрен, сәламәтлек саклау учреждениеләрен, картлар һәм инвалидлар йортларын һ.б. карап тоту һәм алардан дөрес файдалану һ.б..;
кунакханә номерларын җыештыру;
биналарны, торак йортларның баскычларын җыештыру;
түбәләрдән һәм территорияләрдән кар ташу;
киртәләр урнаштыру;
мемориаль плитәләр урнаштыру;
ишекләрне, күпкатлы йортларның подъездлар тәрәзәләрен җылыту;
башка төрле эшләр.

**Транспорт һәм элемтә**
Автобус тукталышларын төзекләндерү һәм җыештыру;
телефон баганаларын алмаштыру;
элемтә линияләрен салу буенча җир эшләре;
автотранспортны юу;
шәһәр пассажир транспорты эшен мониторинглау;
элемтә хезмәтләре белән тәэмин итү;
тимер юл полотносын чистарту;
станция һәм килү юлларын чистарту;
төяү-бушату эшләре;
локомотив депода ярдәмче эшләр;
пассажирлар транспортына, почта һәм элемтә оешмаларына хезмәт күрсәтүдә ярдәм;
халыкка һәм учреждениеләргә транспорт хезмәте күрсәтүдә ярдәм;
җәмәгать транспортында кондукторлар һәм пассажир счетчиклары сыйфатында эшләү;
элемтә бүлекләрендә хат ташучылар эше;
проводник булып эшләү;
станция эшчесе эшләү;
телефон кабелен салу эше;
юл йөрү билетларын тарату;
тимер юл платформаларын кардан чистарту;
тимер юлларны ремонтлау һәм төзү;
сезонлы эшләр (товарларны китерү, кар чистарту һ.б.);
суднолар ремонтлау эшләре;
автотранспорт өчен биналарны җыештыру;
башка эшләр.

**Сәламәтлек саклау, физик культура һәм социаль хезмәт күрсәтү**

Сулыкларны һәм подвалларны дезинсекцияләү;
балалар һәм яшүсмерләрнең сәламәтләндерүен һәм ялын тәэмин итү;
халыкка социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү (яшелчә бакчаларын казу, утын әзерләү, фатирларны косметик ремонтлау һ.б.);
тамаша кылу чараларына (фестивальләр, спорт ярышлары һ.б.) хезмәт күрсәтү;
биналарга хезмәт күрсәтү һәм ремонт;
янәшәдәге территорияләрне яшелләндерү һәм төзекләндерү, ял һәм туризм зоналары;
спорт лагерьларында балаларның ялын оештыру;
пенсия эшләрен рәсмиләштерү;
өске киемне кабул итү һәм бирү;
халыкны һәм муниципаль учреждениеләрне ягулык белән тәэмин итү;
муниципаль берәмлектә физик культураны һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру һәм башкалар.;
кер юу;
Өлкәннәрне, инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны карау;
документларны исәпкә алу һәм рәсмиләштерү;
ветераннар өчен бүләкләр формалаштыру, котлау открыткалары, бәйрәм чараларында катнашу өчен чакырулар һәм аларны адреслы китерү;
башка эшләр.

**Мәгариф, мәдәният, сәнгать һәм фән**

Археологик эзләнүләр башкару;
территорияне төзекләндерү;
җәйге чорда балалар мәйданчыкларында тәрбиячеләр булып эшләү;
аттестатлар тутыру;
экспонатларны һәм экспозиция залларын косметик ремонтлау;
аттракционнарга, мәдәни билгеләнештәге тамашалы чараларга (фестивальләр, бәйрәмнәр, конкурслар) хезмәт күрсәтү;
китапханә өлкәсенә хезмәт күрсәтү;
биналарга, корылмаларга хезмәт күрсәтү;
мәдәният, хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын оештыру;
яшьләрнең ялын оештыру;
Яңа ел чыршысын саклау;
мәдәни-массакүләм чараларны әзерләү һәм уздыру;
Мәктәпкәчә, төп гомуми һәм һөнәри белем бирү муниципаль учреждениеләрен оештыру, карап тоту һәм үстерүдә ярдәм күрсәтү, мәдәният учреждениеләрендә, балалар бакчаларында, пионер лагерьларында балаларның ялын оештыру, аларны карап тоту һәм үстерү, мәктәпкәчә учреждениеләрдә утын яру һәм өю;
лектор-экскурсовод эше;
методист эше;
сәхнәне көйләүче монтажчы эше;
музей-күргәзмә комплексы хезмәткәре эше;
җәйге вакытта балалар мәйданчыкларындагы эшләү;
балигъ булмаганнарның җәйге хезмәтен оештыру буенча эшләр;
китап, мебель ремонтлау;

мемориаль мәйданчыкларны ремонтлау, сугышта катнашучылар һәм ветераннар өчен стендлар, планшетлар, альбомнар ясау;
укучылар бригадалары белән җитәкчелек итү;
мәдәният учреждениеләре эшчәнлеге өчен шартлар тудыру (мебель, җиһазлар урнаштыру, афишалар ябыштыру һ. б.);
балаларны мәктәпкә озату;
башка эшләр.

**Идарә итү**
Архивларны оештыруда һәм карап тотуда ярдәм (архивка тапшыру өчен документлар әзерләү эшләре, хуҗалыкка кагылмаган китапларны аралау һ. б.));
ветераннарның мәгълүмат базаларын чагыштыру;
җирдән файдаланучылар исемлеген төзү;
әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын үткәрүдә катнашу, су объектларыннан файдалануны җайга салу (мелиоратив эшләр башкару, сулыкларны чистарту, коелар төзү һ. б.);
федераль һәм региональ иҗтимагый кампанияләрне (статистик, социологик тикшеренүләр, халык санын алу, авыл хуҗалыгы исәбен алу, терлек башы санын алу, җәмәгатьчелек фикерен сораштырулар үткәрүдә катнашу, сайлау комиссияләрендә эшләү һ. б.);
адреслы хуҗалык торышын тикшерүдә катнашу;
башка эшләр.

**Төрле эшләр**
Машинкада язу эшләрен башкару;
шәхси затлар заявкалары буенча вак ремонт-төзелеш һәм авыл хуҗалыгы эшләрен башкару;
маймыч үрчетү;
яшелчә өчен сетка үрү;
хуҗалык китапларын тутыру;
мех эшләнмәләре җитештерү;
юрган сыру;
урам исемнәре, йорт номерлары язылган табличкаларны яңарту;
экологик эшләрне оештыру һәм үткәрү;
йон эшкәртү;
язгы караванда йөк төяү-бушату эшләре;
укучыларны вакытлыча эш белән тәэмин итү өчен эш урыннары әзерләү;
нәшриятларда ярдәмче эшләр;
гардеробта эшләү;
кастелянша эше;
лаборант булып эшләү;
басма матбугат тарату;
реклама тарату;
геологик экспедицияләрдә сезонлы кыр эшләре;
гуманитар ярдәм сортировкалау;
башка эшләр.